СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2022 г. Заинск № 202

**«Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 13 апрелендәге 280 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәр булмаган белгечләрнең һәм эшчеләрнең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәдә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8 пунктның 1 пунктчасында "10" санын "5" санына алмаштырырга;

1.2. 2.8 пунктның 3 пунктчасында "120" санын "100"санына алмаштырырга;

1.3. 2.8 пунктның 4 пунктчасы дүртенче абзацында "2,5" санын "3,0" санына алмаштырырга;

1.4. "Зәй муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф

челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)" 2 нче кушымтасын өстәргә (кушымта).

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П.С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы
Советының 2022 елның
"04" 03.2022
202 номерлы карарына
кушымта

**Зәй муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)**

| Бердәм тариф челтәре өчен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620,0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1948 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1,2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800,0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклад) күләме җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1-2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.